ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“10” октябрь 2022 ел Мусабай-Завод авылы № 16

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлегенең Мусабай-Завод авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Мусабай-Завод авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 21 октябренә 11.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авылы Якупов, Киров урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Мусабай-Завод авылы, Киров урамы, 36 йорт каршында билгеләргә.

2. 2022 елның 21 октябренә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авылы Ленин, Муса Җәлил урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Мусабай-Завод авылы, Ленин урамы, 31 йорт каршында билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, Мусабай-Завод авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
“Мусабай-Завод авыл җирлегенең Мусабай-Завод авылы территориясендә 2023 елда балигъ булган, Мусабай-Завод авыл җирлегенең Мусабай-Завод авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм кендезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:
- юлларны ремонтлау;
- Мусабай-Завод авылы территориясендә видеокүзәтү сатып алу һәм урнаштыру;
- урам утларын ремонтлауны хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

5. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
6. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
7. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
8. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Мусабай-Завод авыл җирлеге Башлыгы Ф. Ә. Әгъләҗева